**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЯҢА ЧИШМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-20-08, факс: (8-84348) 2-21-73, Nsmsp.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль
районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

29 нчы апрель 2022 ел № 19-70

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советының 2017 елның 26 маендагы 19-68 номерлы карары белән расланган «Яңа Чишмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында»

«Ветеринария турында» 2021 елның 6 декабрендәге 397-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советының 2017 елның 26 маендагы 19-68 номерлы карары белән расланган «Яңа Чишмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләренә ( 08.02.2018 №27-88; 18.05.2018 № 30-97; 31.05.2019 №45-152; 20.03.2021 №7-25 Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советының карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

III бүлекнең 186 пунктындагы 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) терлекләр авыруларын кисәтүне һәм терлекчелек продуктларын ветеринария-санитария ягыннан куркынычсызлыкны тәэмин итә торган хуҗалык һәм ветеринария чараларын башкарырга, терлекчелек биналарын һәм терлек азыгын саклау һәм терлекчелек продуктларын эшкәртү корылмаларын тиешле хәлдә тотарга, әйләнә-тирә мохитне терлекчелек калдыклары белән пычратмаска;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм интернет-телекоммуникация челтәрендәге Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советының Законлылык, җирдән файдалану һәм территорияләрне төзекләндерү буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Яңа Чишмә авыл җирлеге Башлыгы В. М. Козлов